СОВЕТ
СРЕДНЕАТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 2А, д.Нижние Аты,
Арский муниципальный район, 422016

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урамы, 2А йорт, Түбән Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422016

Тел. (84366)5-07-35, факс (843665-07-35). E-mail: Sat.Ars@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«05 » июль 2019 ел № 2

Җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында

Россия Федерациясенең 2003 елның 6 октябрендә чыккан «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 2131-ФЗ номерлы законы, « Урта Аты авыл җирлеге» Уставы һәм хокукый актлар проектлары турында фикер алышуда катнашуда муниципаль берәмлеге халкының хокукларын тәэмин итү максатында 2018 нчы елның 22 октябрендә чыгарылган 72 номерлы Совет караы белән расланган« Урта Аты авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә"гә яраштырып, карар бирәм:

1. « Урта Аты авыл җирлеге » муниципаль берәмлегендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында карар проекты буенча җәмәгать тыңлауларын" 2019 елның 5 августына билгеләргә.
2. « Урта Аты авыл җирлеге » муниципаль берәмлегендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында карар проекты буенча ачык тыңлаулар"ны Арча муниципаль районы, Түбән Аты авылы,Үзәк урам,37 йорт адресы буенча 2019 елның 5 августында 15 сәгатьтә үткәрергә.
3. Гражданнарның муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәрен һәм җәмәгать тыңлауларында катнашу турында язмача гаризаларын 5 августның 17-00 сәгатенә кадәр Арча муниципаль районы, Түбән Аты авылы, Үзәк урам,37 йорт адресы буенча җибәрергә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) , Арча муниципаль районының рәсми сайтында(arsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы ,Арча районы ,Түбән Аты авылы,Үзәк урам,37 йорт ;Урта Сәрдә авылы , Үзәк урам,70а йорт ,Клачы авылы , Аяк киеме урамы ,16 йорт адреслары буенча мәгълүмати стендларда урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Урта Аты авыл җирлеге
Башлыгы

Батталова Р.Х